**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 22 сентябрь | № 679

г. Казань

«Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методика үзәге» дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенең Лениногорск шәһәрендә урнашкан филиалын ябу һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методика үзәге турында» 2003 ел, 15 август, 427 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы вазыйфаи затларын, белгечләрен план буенча әзерләүне, яңадан әзерләүне, аларның квалификациясен күтәрүне камилләштерү, шулай ук Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан нәтиҗәле файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методика үзәге» дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенең Лениногорск шәһәрендә урнашкан филиалын ябу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методика үзәге» дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенең Лениногорск шәһәрендә урнашкан филиалын ябу буенча законнарда каралган чараларны гамәлгә ашырырга, шулай ук Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә учреждениенең әлеге филиалын ябу нәтиҗәсендә эштән

чыгарыла торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның 2 нче пунктын тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетында «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы» ведомствосы буенча «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методика үзәге» дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә каралган акча чикләрендә гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методика үзәге турында» 2003 ел, 15 август, 427 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 8 сентябрь, 443 нче; 2006 ел, 14 август, 409 нчы; 2016 ел, 24 март, 169 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада:

«предприятиеләрнең һәм оешмаларның гражданнар оборонасы граждан оешмалары җитәкчеләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

«Мәгариф турында» Россия Федерациясе Законы» сүзләрен «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы составыннан 64 берәмлектән торган штат саны белән «Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку-укыту-методика үзәге» дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесен (алга таба – уку-укыту-методика үзәге) аерып чыгарырга һәм аңа юридик зат статусын бирергә.

Уку-укыту-методика үзәгенең Әлмәт, Бөгелмә, Зеленодольск, Чаллы, Түбән Кама, Чистай шәһәрләрендә филиаллары бар, дип билгеләргә.»;

5 нче пунктта «яңадан оештырылган дәүләт белем бирү учреждениесенә» сүзләрен «уку-укыту-методика үзәгенә» сүзләренә алмаштырырга;

кушымтада «ДББУ» сүзен «дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков